# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“28” ноябрь 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 28 ноябрендә «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Иске Шимбер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашучы) затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Шимбер авылында үлән чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү ).

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Шимбер авылының урам юлларын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (су чыгару насосы белән идарә итү станциясен ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 33 (утыз өч) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 19 (унтугыз) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 19 (унтугыз) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Иске Шимбер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашучы) затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

   1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Шимбер авылында үлән чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү ).

   2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Шимбер авылының урам юлларын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

   3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (су чыгару насосы белән идарә итү станциясен ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә мәсьәләләрен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы: Галиәхмәтов Д.М.